Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы Яңа Нәдер авыл җирлегенең
Яңа Нәдер авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы карары

28 ноябрь 2022 ел № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, 2022 елның 25 ноябрендә 17 сәгать 00 минутта, 2022 елның 26 ноябрендә 13 сәгать 00 минутта, 2022 елның 27 ноябрендә 13 сәгать 00 минутта узган гражданнарның этаплы җыен нәтиҗәләре нигезендә түбәндәге "Сез 2023 елда Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Яңа Нәдер авыл җирлеге Яңа Нәдер авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган һәр кешедән 400 сум күләмендә үзара салым кертүгә, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә хәрби хезмәткә чакырылган гражданнардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан (ата-аналары, хатыны, балаларыннан), күп балалы гаиләләр һәм 1 төркем инвалидлардан тыш һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрүгә юнәлдерү белән килешәсезме: су белән тәэмин итү системасын норматив хәлгә китерү, су белән тәэмин итү системасын норматив хәлгә китерү өчен җиһазлар сатып алу; урам утларын һәм юлларны норматив хәлгә китерү, сметалар төзү, техник күзәтчелек үткәрү һәм җирлек милкенә рәсмиләштерү өчен түләүгә ризамы?" соравы буенча гражданнар җыены беркетмәсе төзелде.

Гражданнар җыенының нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 1055 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 597 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

гражданнар җыенында катнашучыларның 597 «РИЗА» позициясе өчен тавыш бирде; катнашучыларның 0 «КАРШЫ» позициясе өчен тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Яңа Нәдер авыл җирлегенең Яңа Нәдер авылында гражданнар җыенын узган дип танырга, гражданнар җыенының нәтиҗәләре - чынбарлыкка туры килә.

2. "Сез 2023 елда Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Яңа Нәдер авыл җирлеге Яңа Нәдер авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган һәр кешедән 400 сум күләмендә үзара салым кертүгә, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә хәрби хезмәткә чакырылган гражданнардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан (ата-аналары, хатыны, балаларыннан), күп балалы гаиләләр һәм 1 төркем инвалидлардан тыш һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрүгә юнәлдерү белән килешәсезме: су белән тәэмин итү системасын норматив хәлгә китерү, су белән тәэмин итү системасын норматив хәлгә китерү өчен җиһазлар сатып алу; урам утларын һәм юлларны норматив хәлгә китерү, сметалар төзү, техник күзәтчелек үткәрү һәм җирлек милкенә рәсмиләштерү өчен түләүгә ризамы?" турындагы мәсьәлә буенча карарны кабул ителгән дип танырга.

3. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, Яңа Нәдер авылы, Совет урамы, 81 йорт территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында халыкка игълан итәргә, «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә Әлмәт муниципаль районы сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Яңа Нәдер авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Яңа Нәдер авыл җирлеге башлыгы С.М. Миннебаев